Тукай муниципаль районы
Иске Абдул авыл җирлеге
Торнаташ авылы

# ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

«23» ноябрь 2024 ел № 01

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Торнаташ авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2025 елда яшәү урыны буенча Иске Абдул авыл җирлеге Торнаташ авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә һәм өлешчә мобилизацияләү буенча РФ Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлтергә:
- Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (брусчатка, бордюр ташы, Торнаташ авылындагы Бөек Ватан сугышы һәйкәле рәшәткәләре сатып алу);
- урамнарны яктырту җайланмасы (Электроматериаллар сатып алу, Торнаташ авылында урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру).

2. Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Торнаташ авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Торнаташ авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек
Иске Абдул авыл җирлеге Баш… Р.Х.Сафина